Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты

16.12.2021ел №46

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координация советын төзү турында

"Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында" 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль закон, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Идел буе авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координацион совет (№1 кушымта) төзергә.
2. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы Ямбакты авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча Координация советы турында Нигезләмәне (2 нче кушымта) расларга.
3. Әлеге карарны Спас муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Ямбакты авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И.Ә.Гәләветдинов

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Ямбакты авыл җирлеге  Башкарма комитетының 2021 елның
16.12..2021ел
№46 карарына
1 нче кушымта.

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының
Ямбакты авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү буенча координация советы составы

1.Гәләветдинов Илшат Ахатович - авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе

2. Хәйруллин Раил Равилович-депутат

3. Шайхутдинова Рәмзия Фоатовна- авыл җирлеге башкарма комитеты сәркатибе

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы
Ямбакты авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның
16.12.2021ел
№46 карарына.
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районы авы Ямбакты авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча Координация советы турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча Координация советы (алга таба-Координация советы) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә даими эшләүче киңәшмә органы булып тора.
1.2. Координация Советы Карарлары тәкъдим итү характерына ия.

2. Координация советының максатлары

Координация советының максатлары булып торалар:
1) Ямбакты авыл җирлеге территориясендә дәүләт һәм төбәк сәясәтен гамәлгә ашыруга кече һәм урта эшкуарлык субъектларын җәлеп итү;
2) Ямбакты авыл җирлегенең кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүгә юнәлдерелгән инициативаларны күрсәтү һәм аларга ярдәм итү;
3) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү өлкәсендә өстенлекләрне билгеләгәндә тәкъдимнәр эшләү;
4) гражданнарның эшкуарлык эшчәнлегенә хокукларын гамәлгә ашыруга кагылышлы һәм күрсәтелгән мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр әзерләүгә кагылышлы мәсьәләләр буенча фикер алышуга гражданнарны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен җәлеп итү;
5) кече һәм урта эшкуарлыкны үстерүне җайга сала торган норматив хокукый актлар проектларына иҗтимагый экспертиза уздыру.

3.Координация советы функцияләре

Куелган максатларны хәл итү өчен координация советы:
3.1. Кече һәм урта эшкуарлык субъектлары эшчәнлегенең норматив хокукый нигезләрен камилләштерү, Ямбакты авыл җирлеге территориясендә эшкуарлыкны үстерүгә комачаулаучы административ киртәләрне киметү мәсьәләләрен карый.
3.2. Ямбакты авыл җирлеге территориясендә кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм итү системасының гамәли тәҗрибәсен анализлый.
3.3. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының, эшмәкәрләр берләшмәләренең гаризаларын, тәкъдимнәрен һәм дәгъваларын карый, тиешле рекомендацияләр һәм тәкъдимнәр эшли.
3.4. Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының мөрәҗәгатен һәм Ямбакты авыл җирлегенең кече һәм урта эшкуарлык субъектларына мөлкәти ярдәм алуга һәм арендага алынган мөлкәтне сатып алуның өстенлекле хокукын гамәлгә ашыруга карата карарлары һәм норматив актлары проектларын карый.

3.5. Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, җирле үзидарә органнары, муниципаль учреждениеләр, кече һәм урта эшкуарлыкка ярдәм инфраструктурасын барлыкка китерүче оешмалар, кече һәм урта эшкуарлык субъектлары һәм аларның коммерциягә карамаган берләшмәләре белән хезмәттәшлек итә.

3.6.Спас муниципаль районы органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль бүлекчәләренең вазыйфаи затларының координация советы утырышларында, кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының коммерциягә карамаган оешмалары җитәкчеләрен (вәкилләрен) катнашырга чакыра.

3.7. Гражданнарны, иҗтимагый берләшмәләрне һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләрен эшкуарлык эшчәнлегенә гражданнарның хокукларын гамәлгә ашыруга кагылышлы мәсьәләләр буенча фикер алышуга һәм күрсәтелгән мәсьәләләр буенча тәкъдимнәр эшләүгә җәлеп итә.

3.8. Координация советы эшенә Спас муниципаль районының бәйсез экспертларын һәм эшкуарларын җәлеп итә.

3.9. Ямбакты авыл җирлеге территориясендә җирле үзидарә органнарына, муниципаль инфраструктура оешмаларына, коммерциягә карамаган кече һәм урта эшкуарлык субъектларына муниципаль ярдәм күрсәтү (шул исәптән мөлкәти) һәм эшкуарлыкны үстерү мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр әзерли.

3.10.Эшкуарлык үсешенә комачаулый торган административ киртәләрне бетерү мәсьәләләре буенча Ямбакты авыл җирлеге, Спас муниципаль районы җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү буенча тәкъдимнәр эшли.

## 4. Координация советы составы.

4.1. Координация советының персональ составы Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән раслана.

4.2.Координация советы составына координация советы рәисе, координация советы секретаре, координация советы әгъзалары һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъекты вәкилләре керә.

4.3.Координация советы рәисе булып Ямбакты авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тора.

## 5. Координация советы эшчәнлеген оештыру.

5.1. Координация советы рәисе:

- Координация советы эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра:

- Координация советы утырышларын алып бара;

-Координация советы утырышы беркетмәсенә һәм координация советы утырышы беркетмәсеннән өземтәгә кул куя;

- Координация советы карарларының үтәлешен тәэмин итә һәм контрольдә тота.

5.2. Координация советы секретаре:

- утырышның көн тәртибенә кертелгән мәсьәләләрне карау өчен кирәкле документлар һәм материаллар җыя һәм координация советы әгъзаларын кирәкле документлар һәм материаллар белән тәэмин итә;

-Координация советы утырышларын әзерләүне оештыра, шул исәптән координацион совет утырышы башланырга өч көннән дә соңга калмыйча координацион совет әгъзаларына һәм чакырылган затларга Координация советы утырышының датасы, вакыты, урыны һәм көн тәртибе турында хәбәр итә;

- Координация советы утырышы беркетмәсен алып бара;

- Координация советы утырышлары беркетмәләренә кул куя;

- Координация советы утырышлары материаллары һәм беркетмәләре саклауны тәэмин итә;

5.3. Координация советы утырышлары кирәк булган саен, әмма елына кимендә ике тапкыр уздырыла.

5.4. Координация советы утырышы, әгәр анда Координация советы әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы дип санала.

5.5. Координация Советы карарлары ачык тавыш бирү юлы белән Координация советы әгъзаларының күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм беркетмә төзелә.

6. Координация советы эшчәнлеген тәэмин итү.

Координация советы эшчәнлеген техник, оештыру һәм мәгълүмати-аналитик тәэмин итү Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының Ямбакты авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан гамәлгә ашырыла.